ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 576-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Э.Ю. Габдуллаҗанов, Д.В. Анисимов, А.Ю. Егоров, О.Ю. Николаев, К.Г. Садриев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 576-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 11 июле
№ 2574-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Э.Ю. Габдуллаҗанов,
Д.В. Анисимов, А.Ю. Егоров,
О.Ю. Николаев,
К.Г. Садриев тарафыннан
кертелә

**«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 11 (I өлеш); 2015, № 12 (I өлеш); 2016, № 1 – 2, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 38 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш); 2022, № 57 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш), № 34 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $2^1$ статьяда:
а) «аны актуальләштергәндә» сүзләрен «аңа үзгәрешләр керткәндә» сүзләренә алмаштырырга;
б) 10 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

2) 3 статьяда:
а) 1 өлештә:
4 пунктта «, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программага кертелергә тиешле өстәмә белешмәләрне билгеләү» сүзләрен төшереп калдырырга;
5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«5) күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны әзерләгәндә һәм раслаганда яисә аңа үзгәрешләр керткәндә мондый программага кертелгән күпфатирлы йортларның техник торышын тикшерүне үткәрүне оештыру тәртибен, мондый күпфатирлы йортларның техник торышын тикшерү нәтиҗәләрен исәпкә алу тәртибен билгеләү;»;
$13^4$ пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«$13^4$) аварияне, башка табигый яисә техноген характердагы гадәттән тыш хәлне бетерү өчен кирәкле булган күләмдә күпфатирлы йортның техник торышын торгызу максатларында аның гомуми мөлкәтенә капиталь ремонт ясаган очракта, бу

күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми җыелышын үткәрмичә генә күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау турында карар кабул итү тәртибен билгеләү;»;

$13^8$ пунктта «идарә итүне» сүзләрен «идарә итү эшчәнлеген» сүзләренә алмаштырырга, «билгеләнә,» сүзеннән соң «шулай ук, әгәр мондый күпфатирлы йортларның техник торышын тикшерү Россия Федерациясе Торак кодексының 167 статьясындагы 2 өлешендә нигезендә үткәрелгән булса, күпфатирлы йортларның техник торышын тикшерү нәтиҗәләре хакында» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:

«$1^1$. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күпфатирлы йортларның техник торышына дәүләт мониторингы үткәрү тәртибе турында норматив хокукый акт кабул итәргә хокуклы, аның кысаларында Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең архитектура, шәһәр төзелеше, төзелеш, төзелеш материаллары сәнәгате өлкәсендәге, торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендәге органы (алга таба – вәкаләтле орган) тарафыннан күпфатирлы йортларның техник торышы һәм аның үзгәрү динамикасы хакында мәгълүмат җыю, аны системалаштыру, анализлау гамәлгә ашырыла. Әлеге дәүләт мониторингы үткәрү тәртибенә әлеге статьяның 1 өлешендәге 5 пунктында каралган күпфатирлы йортларның техник торышын тикшерүне үткәрүне оештыру тәртибе керергә мөмкин»;

в) 2 өлештә:

беренче абзацта «Архитектура, шәһәр корылышы, төзелеш, төзелеш материаллары сәнәгате өлкәсендәге, торак һәм коммуналь хуҗалык өлкәсендәге Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының (алга таба – вәкаләтле орган)» сүзләрен «Вәкаләтле органның» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Россия Федерациясенең техник җайга салу законнары һәм Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә күпфатирлы йортларның техник торышына эксплуатация контроле үткәрү тәртибен билгеләү;»;

3 пунктка «тәртибен» сүзеннән соң «, әлеге затлар тарафыннан тапшырылырга тиешле башка белешмәләр исемлеген һәм аларны тапшыру тәртибен» сүзләрен өстәргә;

3) 5 статьяның $3^1$ өлешендә «карар» сүзен «норматив хокукый акт» сүзенә алмаштырырга;

4) 10 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10 статья. **Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программа әзерләү һәм раслау, аңа үзгәрешләр кертү тәртибе, мондый программага таләпләр, аны әзерләү, аңа үзгәрешләр кертү өчен кирәкле белешмәләрне җирле үзидарә органнары һәм капиталь ремонт фондларын махсус счетта булдыручы урыннар милекчеләре тарафыннан бирү тәртибе**

1. Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны (алга таба – капиталь ремонт буенча региональ программа)

әзерләү һәм раслау, аңа үзгәрешләр кертү Россия Федерациясе Торак кодексы һәм әлеге Закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Капиталь ремонт буенча региональ программа Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау өчен кирәкле срокка төзелә.

Капиталь ремонт буенча региональ программа Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

4. Капиталь ремонт буенча региональ программага түбәндәгеләр керә:

1) капиталь ремонт буенча региональ программаның төп максатлары һәм бурычлары;

2) капиталь ремонт буенча региональ программаны үтәүнең планлаштырыла торган күрсәткечләре;

3) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан (шул исәптән барлык бинаолары бер милекчегә караган күпфатирлы йортлар) һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан расланган күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча муниципаль адреслы программаларга (алга таба – капиталь ремонт буенча муниципаль адреслы программа) кертелгән барлык күпфатирлы йортлар исемлеге, моңа Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиеш дип танылган күпфатирлы йортлар керми;

4) күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр исемлеге;

5) күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауның план чоры, шул исәптән, Россия Федерациясе Торак кодексының 166 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында каралган хезмәтләрне һәм (яисә) эшләрне бер үк вакытта күпфатирлы йортның йорт эчендәге ике һәм аннан күбрәк инженерлык системаларына карата күрсәтүнең һәм (яисә) башкаруның Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты норматив хокукый актында каралган зарурлыгын исәпкә алып, хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең һәр төре буенча башкару сроклары, шул ук вакытта әлеге срок календарь елны яисә мондый ремонт ясалырга тиешле өч календарь елдан артып китмәгән чорны күрсәтеп билгеләнергә мөмкин;

6) региональ оператор тарафыннан капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләменнән чыгып булдырылган капиталь ремонт фонды акчалары исәбеннән түләнергә мөмкин булган күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең иң чик бәясе күләме;

7) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты норматив хокукый акты нигезендә капиталь ремонт буенча региональ программага кертелергә тиешле башка белешмәләр.

4. Капиталь ремонт буенча региональ программаны әзерләү вәкаләтле органның карары белән гамәлгә ашырыла. Әлеге карар аны кабул итү көненнән алып 7 көн эчендә капиталь ремонт буенча муниципаль адреслы программалар әзерләү өчен җирле үзидарә органнарына җибәрелә.

5. Җирле үзидарә органнары вәкаләтле органның әлеге статьяның 4 өлешендә күрсәтелгән карарын алган көннән алып ике ай эчендә капиталь ремонт буенча муниципаль адреслы программалар әзерләүне һәм раслауны гамәлгә ашыра. Расланган капиталь ремонт буенча муниципаль адреслы программа аны раслаган

көннән алып бер айдан да соңга калмыйча җирле үзидарә органы тарафыннан вәкаләтле органга тапшырыла. Вәкаләтле орган әлеге капиталь ремонт буенча муниципаль адреслы программаларны тапшыру көненнән алып бер ай эчендә капиталь ремонт буенча региональ программа проектын әзерләүне гамәлгә ашыра һәм аны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына раслау өчен җибәрә.

6. Капиталь ремонт буенча региональ программага үзгәрешләр кимендә елга бер мәртәбә кертелә.

7. Капиталь ремонт буенча региональ программага үзгәрешләр кертү турында карар вәкаләтле орган тарафыннан күпфатирлы йортлар белән идарә итүне гамәлгә ашыручы затлар, шул исәптән капиталь ремонт фондын махсус счетта булдыручы күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре тапшырган мондый программага үзгәрешләр кертү өчен кирәкле белешмәләр, шулай ук әлеге затлар алар хакында белешмәләр тапшырмаган күпфатирлы йортлар буенча мөстәкыйль алынганнары нигезендә әзерләнгән җирле үзидарә органнары тәкъдимнәре буенча кабул ителә. Бу карар федераль башкарма хакимиятнең торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы орган тарафыннан расланган методик тәкъдимнәр нигезендә кабул ителә.

8. Җирле үзидарә органнары вәкаләтле орган тарафыннан капиталь ремонт буенча региональ программага үзгәрешләр әзерләү турында карар кабул ителгән көннән алып бер ай эчендә капиталь ремонт буенча муниципаль адреслы программаларга үзгәрешләр кертә һәм әлеге карар кабул ителгән көннән алып ике айдан да соңга калмыйча аларны вәкаләтле органга тапшыра. Вәкаләтле орган әлеге капиталь ремонт буенча муниципаль адреслы программаларны тапшыру көненнән алып бер ай эчендә капиталь ремонт буенча региональ программага үзгәрешләр әзерләүне гамәлгә ашыра һәм мондый үзгәрешләрнең проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына раслау өчен җибәрә.

9. Капиталь ремонт буенча региональ программага күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауның билгеләнгән срогын соңрак чорга күчерүне, күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча планлаштырыла торган хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр төре исемлеген кыскартуны күздә тота торган үзгәрешләрне кертү урыннар милекчеләре гомуми җыелышының тиешле карары булганда гамәлгә ашырыла, моңа түбәндәге очраклар керми:

1) күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча планлаштырыла торган хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр төренең исемлеген кыскарту капиталь ремонт үткәрелергә тиешле конструктив элементларның булмавына бәйле булса;

2) күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең планлаштырылган төре элегрәк үткәрелгән булса һәм шул ук вакытта күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау кирәклеген билгеләү тәртибендә яңадан мондый хезмәтләр күрсәтү һәм (яисә) эшләр башкару капиталь ремонт буенча региональ программада билгеләнгән срокта таләп ителми дип билгеләнсә;

3) капиталь ремонт фонды булдыру ысулын үзгәртү Россия Федерациясе Торак кодексының 189 статьясының 7 өлешендә каралган нигезләрдә башкарылса.

Бу очракта капиталь ремонт ясау вакыты күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау кирәклеген билгеләү тәртибендә билгеләнә.

4) урыннар милекчеләренең, һәм (яисә) күпфатирлы йорт белән идарә идарә итүне гамәлгә ашыручы затның, һәм (яисә) күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту һәм ремонтлау эшләрен башкаручы затның мондый хезмәтләр күрсәтүгә һәм (яисә) эшләр башкаруга подряд оешмасын күпфатирлы йорттагы урыннарга һәм (яисә) күпфатирлы йортның төзелеш конструкцияләренә, инженерлык челтәрләренә, күпфатирлы йортның санитария-техника, электр, механика һәм башка җайланмаларына кертмәүдә чагылган комачаулык итүенә бәйле рәвештә күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәтләр күрсәтүнең һәм (яисә) эшләр башкаруның (шул исәптән элегрәк башланган хезмәтләр күрсәтүне һәм (яисә) эшләр башкаруны тәмамлауның) мөмкин булмавы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты норматив хокукый актында билгеләнгән тәртиптә билгеләнсә;

5) капиталь ремонт буенча региональ программага үзгәрешләр кертү йорт эчендәге газ белән тәэмин итү инженерлык системаларын ремонтлау, лифтларны ремонтлау, алмаштыру, модернизацияләү, лифт шахталарын, машина һәм блок бүлмәләрен ремонтлау эшләрен башкару срокларының үзгәртелүенә бәйле булса.

6) күпфатирлы йортның техник торышын тикшерү нәтиҗәләре буенча капиталь ремонт буенча региональ программада каралган күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яисә) эшләр башкару билгеләнгән срокта таләп ителми дип билгеләнсә.

10. Капиталь ремонт буенча региональ программага үзгәрешләр кертү өчен капиталь ремонт буенча региональ программага кертелгән күпфатирлы йортның техник торышын тикшерү нәтиҗәләре, әгәр мондый күпфатирлы йортның техник торышын тикшерү Россия Федерациясе Торак кодексының 167 статьясының 2 һәм 3 өлешләре нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты хокукый акты йә күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми җыелышы карары нигезендә үткәрелгән булса, нигез булып тора.

11. Капиталь ремонт буенча региональ программага әлеге статьяның 9 өлешендәге 4 пунктында каралган нигездә кертелгән үзгәрешләр, тиешле хәлләрне бетергәннән соң, күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәтләр күрсәтүнең һәм (яисә) эшләр башкаруның (шул исәптән элегрәк башланган хезмәтләр күрсәтүне һәм (яисә) эшләрне башкаруны тәмамлауның) план чорын күздә тотарга тиеш. Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча планлаштырыла торган хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр төренең исемлеген әлеге статьяның 9 өлешендәге 4 пунктында каралган нигездә кыскарту рөхсәт ителми.

12. Капиталь ремонт буенча региональ программа Россия Федерациясе Торак кодексының 168 статьясындагы 8 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан дәүләт мәгълүмат торак-коммуналь хуҗалык системасында урнаштырылырга тиеш.»;

5) $10^1$ статьяда:

а) исемдә «төзү һәм раслау» сүзләрен «әзерләү һәм раслау, аларга үзгәрешләр кертү» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 өлештә «үзе билгеләгән тәртиптә» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 3 өлешнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) аварияне, башка табигый яисә техноген характердагы гадәттән тыш хәлне бетерү өчен кирәкле булган күләмдә Россия Федерациясе Торак кодексының 189 статьясындагы $6^1$ өлешендә каралган тәртиптә күпфатирлы йортның техник торышын торгызу максатларында аның гомуми милкәтенә капиталь ремонт ясау очракларын исәпкә алу.»;

г) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ өлеш өстәргә:

«$3^1$. Капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планнарын әзерләү һәм раслау тәртибе, мондый планнарга таләпләр, аларны әзерләү, аларга үзгәрешләр кертү өчен кирәкле белешмәләрне җирле үзидарә органнары һәм капиталь ремонт фондларын махсус счетта булдыручы күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре тарафыннан бирү тәртибе Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән билгеләнә.»;

6) «нигезендә» сүзеннән соң «, шулай ук, әгәр күпфатирлы йортларның техник торышын тикшерү Россия Федерациясе Торак кодексының 167 статьясының 2 һәм 3 өлешләре нигезендә үткәрелгән булса, мондый тикшерү нәтиҗәләре нигезендә» сүзләрен өстәргә;

7) 13 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә төзелгән торак милекчеләре ширкәтләренә, торак, торак-төзелеш кооперативларына, идарәче оешмаларга, региональ операторга дәүләт ярдәме, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты норматив хокукый актлары белән билгеләнгән таләпләрне үтәү шарты белән, әгәр әлеге ярдәмне гамәлгә ашыруга тиешле акчалар Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында каралган булса, күпфатирлы йортларда гомуми милкәткә капиталь ремонт ясауга, шул исәптән кредитлар яисә заемнар буенча гарантияләр, поручительлекләр бирүгә, капиталь ремонт буенча региональ программага кертелгән күпфатирлы йортларның техник торышын тикшерүгә бирелә.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктының «б» пунктчасыннан һәм 2 пунктының «в» пунктчасындагы бишенче абзацыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктының «б» пунктчасы һәм 2 пунктының «в» пунктчасындагы бишенче абзацы әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты Татарстан Республикасы законнарын федераль законнарга туры китерү максатларында эшләнде.

«Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 27 ноябрендәге 561-ФЗ номерлы Федераль закон белән Россия Федерациясе Торак кодексына күпфатирлы йортларның техник торышын тикшерүне үткәрү турында гомуми нигезләмәләрне беркетүгә юнәлдерелгән комплексы үзгәрешләр кертелде. Шуңа бәйле рәвештә Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан күпфатирлы йортларга капиталь ремонтны тиешлечә ясауга юнәлдерелгән норматив хокукый актларны кабул итү нигезләре һәм аларның җайга салу предметы төгәлләштерелде.

Аерым алганда, мондый норматив хокукый актларга түбәндәгеләр кертелде: күпфатирлы йортларның техник торышына эксплуатация контроле үткәрү тәртибе, күпфатирлы йортларның техник торышын тикшерүне үткәрүне оештыру тәртибе; күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны (алга таба – капиталь ремонт буенча региональ программа) әзерләгәндә, раслаганда яисә аңа үзгәрешләр керткәндә мондый тикшерү нәтиҗәләрен исәпкә алу тәртибе. Шулай ук Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органнары күпфатирлы йортларның техник торышына дәүләт мониторингы үткәрү тәртибе турында норматив хокукый акт кабул итәргә хокуклы, аның кысаларында субъектның вәкаләтле башкарма хакимият органы тарафыннан күпфатирлы йортларның техник торышы һәм аның үзгәрү динамикасы хакында мәгълүмат җыю, аны системалаштыру, анализлау гамәлгә ашырыла.

Закон проекты белән «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (алга таба – 52-ТРЗ номерлы Закон) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының югарыда күрсәтелгән мәсьәләләрне җайга салу вәкаләтләрен билгели торган шундый ук үзгәрешләрне кертү тәкъдим ителә.

Шулай ук капиталь ремонт буенча региональ программа әзерләү һәм раслау, аңа үзгәрешләр кертү тәртибен төгәлләштерү, мондый программага таләпләр, аны әзерләү, аңа үзгәрешләр кертү өчен кирәкле белешмәләрне җирле үзидарә органнары һәм капиталь ремонт фондларын махсус счетта булдыручы урыннар милекчеләре тарафыннан бирү тәртибе дә күздә тотыла. Капиталь ремонт буенча региональ программага үзгәрешләр кимендә елга бер мәртәбә, капиталь ремонт буенча региональ программаны әзерләү тәртибе кебек тәртиптә, ягъни расланган капиталь ремонт буенча муниципаль адреслы программалар нигезендә, кертелә дип билгеләнә.

Закон проектында күпфатирлы йортның техник торышына үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре капиталь ремонт буенча региональ программага капиталь ремонт ясауның срогын күчерү, әгәр мондый күпфатирлы йортның техник торышын тикшерү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты хокукый акты йә күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми җыелышы карары нигезендә үткәрелгән булса, капиталь ремонт ясау чиратлылыгын билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү өчен нигез булып тора дип беркетелә.

Закон проекты белән капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планнарын әзерләүгә һәм раслауга, аларга үзгәрешләр кертүгә юнәлдерелгән нигезләмәләр төгәлләштерелә. Аерым алганда, мондый планнарны аварияне, табигый яисә техноген характердагы башка гадәттән тыш хәлне бетерү өчен кирәкле булган күләмдә күпфатирлы йортның техник торышын торгызу максатларында капиталь ремонт ясау очракларын исәпкә алып формалаштыру күздә тотыла.

Закон проекты белән тәкъдим ителә торган үзгәрешләр капиталь ремонтлауны оештыру системасын камилләштерергә, шулай ук милекчеләрнең күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертем буларак түләнә торган акчаларыннан файдалану нәтиҗәлелеген арттырырга ярдәм итәчәк.

**«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарының үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә башкаларын кабул итү таләп ителми.

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының түбәндәге норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү таләп ителәчәк:

1) «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауның региональ программасын раслау турында» 2013 елның 31 декабрендәге 1146 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына;

2) «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауның региональ программасын гамәлгә ашыруның кыска сроклы планнарын раслау тәртибен билгеләү турында» 2017 елның 20 мартындагы 155 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына;

3) «Авария, башка табигый яисә техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыккан очракта, Россия Федерациясе Торак кодексының 189 статьясындагы 5 өлешенең 1 һәм 2 пунктларында каралган мәсьәләләр буенча карар кабул итү тәртибен раслау турында» 2017 елның 12 октябрендәге 787 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына;

4) «Җирле үзидарә органнары тарафыннан күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләренә капиталь ремонт фонды булдыру ысуллары турында, капиталь ремонт фонды булдыру ысулын сайлау тәртибе хакында хәбәр итү тәртибен һәм күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләренә һәм күпфатирлы йортлар белән идарә итүне гамәлгә ашыручы оешмаларга күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаның эчтәлеге һәм аларга нигезләнеп капиталь ремонт ясау чиратлылыгы билгеләнә торган күпфатирлы йортлар торышын бәяләү критерийлары турында хәбәр итү тәртибен раслау хакында» 2018 елның 22 августындагы 692 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына;

5) «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларның техник торышына мониторинг үткәрү тәртибен раслау турында» 2022 елның 25 октябрендәге 139/о номерлы Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы боерыгы.

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан капиталь ремонт буенча региональ программаны әзерләгәндә һәм раслаганда яисә аңа үзгәрешләр керткәндә күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программага кертелгән күпфатирлы йортларның техник торышын тикшерүне үткәрүне оештыру тәртибен, шулай ук капиталь ремонт буенча региональ программага кертелгән күпфатирлы йортларның техник торышын тикшерү нәтиҗәләрен исәпкә алу тәртибен билгеләү таләп ителәчәк.

**«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән каплана торган өстәмә чыгымнарны таләп итми.